РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 29.02.2024 **КАРАР**

287

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең белем бирү учреждениеләрендә баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2015 елның 14 майендәге 516 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигендә һәм Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенең социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында норматив хокукый актлар исемлегенә үзгәрешләр кертү кирәклеге турында 2024 елның 16 гыйнварындагы ЭВ-09-25/3433 номерлы хаты буенча, Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошинның 2024 елның 18 гыйнварындагы 1703-АП номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең белем бирү учреждениеләрендә баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве буенча өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2015 елның 14 майендәге 516 номерлы карарының 4.1 пунктын түбәндәге

редакциядә бәян итеп, әлеге карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: «4.1. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре белән берлектә, әлеге карарда каралган, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформаны (алга таба – ҮЦП) куллану юлы белән ҮЦП операторы билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә ташламалар турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче вазифасын вакытлыча башкаручы А.А. Томилин